| ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

13.10.2023                    с. Кильдеево                    4

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уланово  авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү  турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 26 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уланово авылы гражданнарының үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр  кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга ризамы:

- Уланово авылында үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү

«ӘЙЕ»                    «ЮК»

3. Уланово авылы клубында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Уланово авылы, Заозерная урамы, 44 йорт 14.00 сәгатьтә.
4. Җыенны оештыручы итеп Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы                    В. М. Бурдин